ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 май, 2019 ел № 31/6

Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Миничстрлар Кабинетеның 2018 елның 29 декабрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы "Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында" 412 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1262 санлы карары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 санлы Карары белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/8, 2018 елның 08 ноябрендәге 27/10 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 21 пунктта «аерым оешмалар» сүзләреннән соң «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» Муниципаль бюджет учреждениесеннән тыш,» сүзләрен өстәргә;

2) Түбәндәге эчтәлектәге 21.1 пунктын өстәргә:

«21.1. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» Муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме:

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Җитәкче | 27 800 |
| Җитәкченең беренче урынбасары, җитәкче урынбасары | 26 200 |
| Бүлек башлыгы | 20 500 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 18 450 |
| Баш белгеч | 16 800 |
| Әйдәп баручы белгеч | 15 300». |

2. Шәһәр Советының 2018 елның 08 ноябрендәге 27/9 санлы Карары белән расланган физик культура һәм спорт муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6 санлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 5 пункттагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айлык база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Аттестация узып, "бакалавр", "магистр" яки "дипломлы белгеч" квалификациясе белән раслanучы югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 9 489 | - | - |

| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча инструктор | 9 489 | 11 680 | 14 200 |
| | Спорт буенча инструктор | - | 11 680 | 14 200 |
| | Спортчы-инструктор | 9 489 | - | - |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау буенча техник | - | 11 680 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча инструктор | - | 11 687 | 14 220 |
| | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты | - | 11 687 | 14 220 |
| | Тренер | - | 11 687 | 14 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Физкультура-спорт оешмаларының өлкән инструктор-методисты | - | 11 693 | 14 232»; |

1) 39 пункттагы 7 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«7 нче таблица

Физик культура хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының тулаем чик күләме

| N | Вазыйфа исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәү коэффициентларының тулаем чик күләме |
|---|---|---|---|
| 1. Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме (1төркем) | | | |
| 1.1 | Спортчы | икенче | 5 |
| 2. Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме (2 төркем) | | | |
| 2.1. | Спорт инструкторы | беренче | 45 |
| 2.2. | Спортчы-инструктор | беренче | 45 |
| 2.3. | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау буенча техник | беренче | 45 |
| 2.4. | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты | икенче | 50 |
| 2.5. | Тренер | икенче | 50 |
| 2.6. | Физкультура-спорт оешмаларының өлкән инструктор-методисты | өченче | 55». |

3. Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 26/8 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2018 елның 08 ноябрендәге 27/10 санлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә

1) муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезнамәдә:

- 3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә мәшгуль хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, гомуми белем бирү оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренең (алга таба - мәгариф хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү (хезмәт хакы) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:»;

- 7 пункт таблицасындагы 5 графада «кече тәрбияче юлында «10 020» санын төшереп калдырырга;

- 12 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакыты (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгате нормасы) атнага 36 сәгатьтән дә артмаган кыскартылган эш вакытыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә укыту (уку), тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи бурычлар һәм эш вакыты режимы белән каралган башка педагогик эшне ала.»;

- 14 пунктның 1 пунктчасындагы бишенче абзацта «(рус булмаган)» сүзләрен төшереп калдырырга;

-19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Язма эшләрне тикшерү (дәфтәрләрне тикшерү) өчен түләү түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$B_{nz}^{pt} = \left( \sum O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{pt},$$

анда:

$B_{nz}^{pt}$ - язма эшләрне тикшерү (дәфтәрләрне тикшерү) өчен түләү күләме;

$O_b$ - гомуми белем бирү оешмасы педагогик хезмәткәренең база оклады күләме;

$H_f$ - гомуми белем бирү оешмасында фән буенча педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ - гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең факттагы саны;

$H_N$ - гомуми белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүнең база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$ - гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P - китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш;

$D_{pt}$ - әлеге Нигезнамәнең 20 пунктындагы 1 нче таблицасында күрсәтелгән язма эшләрне тикшерү өчен өстәмә түләү күләме (дәфтәрләрне тикшерү).»;

- 3 таблицаның 7 пунктындагы 2 графаның 30 пунктында «("башлангыч мәктәп - балалар бакчасы", "прогимназия" статусына ия булганнардан тыш) » сүзләрен төшереп калдырырга;

- 3 таблицаның 7 пунктындагы 3 графаның 30 пунктында «төп эш урыны» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа» сүзләрен өстәргә;

- түбәндәге эчтәлектәге 40.1 пунктын өстәргә:

«40.1. Мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр түбәндәге формула белән исәпләнә:

$$B_{sr} = \left( O_b \times \frac{H_f \times Y_f}{H_N \times Y_N} + P \right) \times D_{sr},$$

анда:

$B_{sr}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен түләү;

$O_b$ - гомуми белем бирү оешмасы педагогик хезмәткәрләренең база оклады күләме;

$H_f$ - гомуми белем бирү оешмасының педагогик эш алып бару сәгатьләренең факттагы саны;

$Y_f$ - мәгариф хезмәткәрләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең факттагы саны;

$H_N$ - гомуми белем бирү оешмасы мәгариф хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүнең база ставкасы өчен сәгать нормасы;

$Y_N$ - гомуми белем бирү оешмасында педагогик хезмәткәр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең норматив саны;

P - китап чыгару продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация, уку йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, ләкин төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмаска тиеш;

$D_{sr}$ - хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә түләү 28 процент күләмендә билгеләнә.»;

- 54 пунктта «төп эш урыны» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа» сүзләрен өстәргә;

- 57 пунктта «белем бирү» сүзләрен «гомуми белем бирү» сүзләренә алыштырырга;

- 59 пунктта «белем бирү» сүзләрен «гомуми белем бирү» сүзләренә алыштырырга;

- 67 пунктның бишенче абзацында «төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча мәктәпкәчә белем бирү оешмасы

хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фонды;» сүзләрен «төп вазыйфа( укытучы вазыйфасын биләүче хезмәткәрләрдән тыш) һәм төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) буенча гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фонды);»;

- 67 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы ставкалары) хезмәт өчен түләү фондының 16 проценты күләмендә кабул ителә (укытучы вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш).»

- 1 кушымтада:

- «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» сүзләренә алыштырырга;

Түбәндәге эчтәлектәге 52.1; 52.2 юлларын өстәргә:

| | |
|---|---|
| 52.1 | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 52.2 | Россия Федерациясе балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |

2 пунктта түбәндәге эчтәлектәге 57 юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| 57. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе |

2) муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезнамәдә:

- 11 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакыты (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгате нормасы) атнага 36 сәгатьтән дә артмаган кыскартылган эш вакытыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә укыту (уку), тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи бурычлар һәм эш вакыты режимы белән каралган башка педагогик эшне ала.»;

- 13 пунктның 2 пунктчасындагы тугызынчы абзацта «15» санын «20»санына үзгәртергә;

- 52 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$FOT_{do}$ - төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы

ставкалары) буенча муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фонды (укытучы вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш);»;

- 52пунктның җиденче абзацында «төп эш урыны» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа (укытучы вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

- 53 пунктта «төп эш урыны» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа» сүзләрен өстәргә;

- 68 пункттагы 11 таблицаның «Өстәмәләр билгеләү нигезе» графасында 1 юлда «терәк-хәрәкәт аппараты, интеллект бозылу» сүзләреннән соң «психик үсеш тоткарлану, аутистик үсеш бозылулары, катлаулы дефектлары булган һәм акыл үсеше буенча артта калган балалар белән» сүзләрен өстәргә;

- 1 кушымтада:

- «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» сүзләренә алыштырырга;

2) Түбәндәге эчтәлектәге 52.1; 52.2 юлларын өстәргә:

| | |
|---|---|
| 52.1 | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 52.2 | Россия Федерациясе балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |

3) 2 пунктта түбәндәге эчтәлектәге 57 юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| 57. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе |

4) өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезнамәдә:

- 11 пунктны түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

«Өстәмә белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өчен эш вакыты (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгате нормасы) атнага 36 сәгатьтән дә артмаган кыскартылган эш вакытыннан чыгып билгеләнә, ул үз эченә укыту (уку), тәрбия эшен, шулай ук билгеләнгән тәртиптә расланган вазыйфаи бурычлар һәм эш вакыты режимы белән каралган башка педагогик эшне ала.»;

- 16 пункттагы 1 таблицаның 55 юлында «Тимераякта фигуралы шуу» сүзләрен «Спорт аэробикасы» дип үзгәртергә;

- 89 пунктта «төп эш урыны» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа» сүзләрен өстәргә;

- 103 пунктта:

бишенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«$FOT_{do}$ - төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары (окладлары, хезмәт хакы

ставкалары) буенча өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фонды (укытучы вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш);»;

җиденче абзацта «төп эш урыны» сүзләреннән соң «һәм төп вазыйфа (укытучы вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

- 1 кушымтада:

- «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» сүзләрен «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)» сүзләренә алыштырырга;

Түбәндәге эчтәлектәге 52.1; 52.2 юлларын өстәргә:

| | |
|---|---|
| 52.1 | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |
| 52.2 | Россия Федерациясе балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре |

2 пунктта түбәндәге эчтәлектәге 57 юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| 57. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе |

4. Әлеге Карар рәсми бастырылган көннән үз көченә керә.

Әлеге Карарның 1 пунктының гамәлдә булуы 2019 елның 1 апреленнән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Әлеге Карарның 3 пунктының гамәлдә булуы 2018 елның 1 сентябреннән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев